ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

5 май, 2023 ел № 23/10

Шәһәр Советының 2011 елның 25 августындагы 13/11 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү» 2022 елның 29 декабрендәге 605-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2011 елның 25 августындагы 13/11 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турында Нигезләмәгә (Шәһәр Советының 2015 елның 27 февралендәге 38/8, 2015 елның 9 ноябрендәге 3/5, 2017 елның 24 октябрендәге 20/6, 2018 елның 10 августындагы 26/10, 2018 елның 8 ноябрендәге 27/12, 2019 елның 23 маендагы 31/8, 2020 елның 18 мартындагы 38/6, 2021 елның 4 августындагы 8/10, 2022 елның 2 ноябрендәге 17/10 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 4.1 пунктта «күчемсез» сүзен төшереп калдырырга;

2) 14 пунктта «күчемсез мөлкәт» сүзләрен «күчемле һәм күчемсез мөлкәт» сүзләренә алыштырырга;

3) 63 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«63. Хосусыйлаштырыла торган күчемсез мөлкәткә милек хокукы дәүләт теркәвенә алынган көннән сатып алучыга күчә. Мондый мөлкәтне дәүләт теркәвенә алуга нигез булып күчемсез мөлкәтне сату-алу шартнамәсе, шулай ук кабул итү-тапшыру акты тора.

Хосусыйлаштырыла торган күчемле мөлкәткә милек хокукы сатып алучыга кабул итү-тапшыру акты яклар тарафыннан имзаланган көннән күчә.».

2. Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев